СОВЕТ ШИШИНЕРСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШЕҢШЕҢӘР
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

---

РЕШЕНИЕ
14.04.2025

КАРАР
№ 128

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым һәм үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Балтач районы прокуратурасының гражданнарның үзара салымы турындагы Нигезләмәгә протесты, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Шеңшеңәр авыл җирлеге Уставы нигезендә, Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советы карар чыгарды:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Шеңшеңәр авыл җирлеге Советының 2014 елның 11 апреле №101 карары белән (06.02.2015 №131; 15.11.2017 №64; 31.10.2022 №54 редакциясендә) расланган «Шеңшеңәр авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымы һәм гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турында Нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1.Нигезләмәнең 1.2 пунктындагы 2 нче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гражданнарның үзара салым акчалары дигәндә гражданнарның җирле әһәмияттәге конкрет мәсьәләләрне хәл итү өчен башкарыла торган түләүләре аңлашыла. Гражданнарның үзара салымы тәртибендә түләүләр күләме, исемлектә яшәүчеләрнең гомуми санының 30 процентыннан артыграк була алмаган һәм түләүләр күләме киметелергә мөмкин булган аерым категорияләрдән тыш, җирлектәге барлык кешеләр өчен бертигез дәрәҗәдә билгеләнә.».

1.2. Нигезләмәнең 2.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.1. Әлеге Нигезләмәнең 1.2 пунктының 2 абзацында күрсәтелгән гражданнарның бер тапкыр бирелә торган түләүләрен кертү һәм куллану мәсьәләләре җирле референдумда хәл ителә, ә «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясының 1 өлешенең 4, 4.1 һәм 4.3 пунктларында каралган очракларда, гражданнар җыенында.».

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (www.baltasi.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Шеңшеңәр авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Салихжанов